| | |
|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__02__» ___06____ 2020 ел № __193___

**Балтач муниципаль районында 2020-2023 елларга җылылык чорына әзерлеккә тикшерү үткәрү программасын раслау турында һәм Балтач муниципаль районында 2020-2021 елларга җылыту сезонына әзерлекне бәяләү буенча чаралар үткәрү турында**

Муниципаль районның ягулык - энергетика комплексы предприятиеләрен ягулык сезонына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатыннан, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта нигезендә Балтач муниципаль районында 2020-2023 еллар җылылык сезонына әзерлекне тикшерү программасын расларга.
2. 2020 елның 20 августына кадәр ягулык сезонына әзерлекне бәяләү буенча комиссиягә муниципаль берәмлекләрне, предприятиеләрне һәм учреждениеләрне 2020-2021 елларда җылыту сезонына әзерләүне тәмамларга.
3. 2020 елның 1 сентябренә кадәр җылыту сезонына әзерлекне бәяләү буенча комиссиягә акт һәм 2020-2021 еллардагы җылыту сезонына муниципаль берәмлекнең әзерлек паспортын рәсмиләштерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов